| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**28.07.2017** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 2049** |

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен махсус бүлеп бирелгән урыннарны һәм биналарны билгеләү турында

2017 елның 7 июнендәге«Россия Федерациясенең аерым закон актларына гавами чаралар турында законнарны камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 107-ФЗ номерлы Федераль закон, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә (алга таба - Зеленодольск шәһәре) сайлаучылар белән депутатлар очрашуларын уздыру өчен махсус бүлеп бирелгән урыннарның исемлеген билгеләргә (1 нче кушымта).
2. Депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен Зеленодольск шәһәрендә биналар исемлеген билгеләргә (2 нче кушымта).
3. Депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен Зеленодольск шәһәрендә биналар бирү тәртибен расларга (3 нче кушымта).
4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының (http://pravo.tatarstan.ru) рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) мәгълүмат сайтында урнаштырырга.
5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитетының
Җитәкче вазифаларын башкаручы А. В. Старостин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты
2017 елның 28 июлендәге
2049 номерлы карарына
1нче кушымта ________

**Депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен Зеленодольск шәһәре территориясендә махсус билгеләнгән урыннар исемлеге**

1. Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Зеленодольск шәһәре, Төзүчеләр проспекты, 62 нче йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Метеор» спорт-савыктыру комплексы» муниципаль автоном учреждениесе янәшәсендәге кечкенә мәйдан (автостоянка)
2. Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Зеленодольск шәһәре, Ленин урамы адресы буенча «Зеленодольск музыка театры» муниципаль бюджет учреждениесе белән янәшәдә 13 нче йорт янындагы территория

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты
2017 елның 28 июлендәге
2049 номерлы карарына
2 нче кушымта

,

**Зеленодольск шәһәрендәге биналар исемлеге депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен**

1. Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы , Зеленодольск шәһәре, Ленин ур., 46 нчы йорт адресы буенча урнашкан «Горький исемендәге мәдәният, сәнгать һәм халык иҗаты үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе бинасы
2. Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Зеленодольск шәһәре, Ленин урамы, 13 йорт адресы буенча урнашкан «Зеленодольск музыка театры» муниципаль бюджет учреждениесе бинасы.
3. Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Зеленодольск шәһәре, Комаров урамы, 22 а йорты адресы буенча урнашкан «Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе бинасы

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты
2017 елның 28 июлендәге
2049 номерлы карарына
3 нче кушымта

**Депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен Зеленодольск шәһәрендә биналар бирү тәртибе**

1. Әлеге тәртип 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә эшләнгән һәм Зеленодольск шәһәрендә депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен биналар (алга таба - биналар) бирү тәртибен билгели.
2. Зеленодольск шәһәрендәге депутатлар сайлаучылар белән очрашулар уздыру өчен биналар исемлеге әлеге карарга 2 нче кушымта белән билгеләнә.
3. Сайлаучылар белән очрашулар өчен урыннар биргәндә барлык депутатлар өчен дә тигез шартлар тәэмин ителә.
4. Биналар эш һәм ял (бәйрәм) көннәрендә түләүсез нигездә бирелә.
5. Сайлаучылар белән очрашуга бина бирү өчен депутат Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына (алга таба – Башкарма комитет), очрашу уздырылачак көнгә кадәр 2 атнадан да соңга калмыйча, бина бүлеп бирү турында гариза белән мөрәҗәгать итә.
6. Гаризада чараны үткәрүнең фаразланган датасы, аның башлану вакыты, дәвамлылыгы, катнашучыларның якынча саны, гариза бирү датасы, чараны үткәрү өчен җаваплы кешенең мәгълүматлары, аның контакт телефоны күрсәтелә.
7. Әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән бинаны бүлеп бирү турындагы гариза, мөрәҗәгать итүчегә тиешле җавап биреп, гариза биргән көннән алып өч көн эчендә Башкарма комитет тарафыннан карала.
8. Әгәр дә әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән соралган бина башка депутатка бирелгән булса, яисә мәдәни-массакүләм яки башка чара үткәрүгә җәлеп ителгән булса, Башкарма комитет депутатка башка вакытта шундый ук шартларда бина бирүдән баш тартырга хокуклы түгел.
9. Очрашулар уздырганда иминлекне тәэмин итү Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.
10. Депутатның сайлаучылар белән ачык чара формасындагы очрашулары Россия Федерациясенең җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, йөрешләр һәм пикетлар турындагы законнарына ярашлы рәвештә үткәрелә.